ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

Х. Такташа ул., 94, а/я 44, Казань, 420107

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ ҺӘМ АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮНЕ,
ӘЙЛӘНЕШТӘ ЙӨРТҮНЕ,
СЫЙФАТЫН ДӘҮЛӘТ ТИКШЕРҮЕН
ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ КУЛЛАНУЧЫЛАР
ХОКУКЛАРЫН ЯКЛАУ БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь инспекциясе)

Һ. Такташ урамы, 94 нче йорт, Казан шәһәре, 420107

тел. (843) 278-92-00, факс (843) 278-91-92, e-mail: cla@tatalc.ru, http://www.tatalc.ru,
ОКПО 42151664, ОГРН 1021602865239, ИНН/КПП 1654025044/165901001

**БОЕРЫК**

12.02.2016 Казан шәһәре № 12-07/13

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр итү тәртибен раслау хакында

“Коррупциягә каршы тору турында” 25 декабрь, 2008 ел, № 273-ФЗ Федераль закон, “Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр итү тәртибе һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында” 22 декабрь, 2015 ел, № 650 Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр итү тәртибен (кушымта итеп бирелә) (алга таба – Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе, Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең хокук бүлегенә (Эйдинов Б.Г.) бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

3.Кадрлар бүлеге начальнигы вазыйфаларын башкаручыга (Галкина В.В.) Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең дәүләти гражданлык хезмәткәрләрен, шулай ук, хезмәт контрактларын төзегәндә, гражданнарны бу боерык белән таныштыруны тәэмин итәргә.

4. Коррупцион һәм башка төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы затка бу боерыкны Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми порталындагы Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе сайтына “Коррупциягә каршы тору” бүлегенә урнаштырырга.

5. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.А.Марченко

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 12.02.2016 ел, №12-07/13 боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясендә дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр итү тәртибе**

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасының Этил спирты һәм алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне, сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясендә (алга таба - Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе) үзләренә карата эшкә яллаучы булып Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе җитәкчесе (алга таба – җитәкче) торган дәүләти гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) тарафыннан вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган яки китерү ихтималы булган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр итү процедурасын җайга сала.

2. Вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган яки китерә алу ихтималы булган шәхси кызыксынуның килеп чыгуы турында хәбәр гражданлык хезмәткәре тарафыннан, бу Тәртипкә кушымтада китерелгән формада, язмача уведомление (алга таба – уведомление) рәвешендә тутырылып, җитәкчегә җибәрелә.

3. Җитәкче өч эш көне эчендә уведомлениене, башлангыч төстә карап тикшерү өчен, коррупцион һәм башка хокук бозуларны кисәтү буенча эш өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) җибәрә.

4. Уведомлениене башлангыч төстә карап тикшерү барышында җаваплы зат уведомлениене җибәргән гражданлык хезмәткәреннән уведомлениедә бәян ителгән хәлләр буенча аңлатмалар алуга, дәүләт хакимияте органнарына, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынулы оешмаларга билгеләнгән тәртиптә запрослар җибәрүне тәкъдим итүгә хокуклы.

5. Җаваплы зат уведомлениене башлангыч төстә карап тикшерү нәтиҗәләре буенча нигезле бәяләмә әзерли. Башлангыч карап тикшерү барышында алынган уведомление, бәяләмә һәм башка материаллар, җаваплы зат тарафыннан уведомление кабул итеп алынганнан соң җиде эш көне эчендә,

җаваплы зат тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча комиссия (алга таба – Комиссия) рәисенә тапшырыла.

6. Бу Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән запрослар җибәрелгән очракта, уведомление, бәяләмә һәм башка материаллар җаваплы зат тарафыннан Комиссия рәисенә уведомление алынганнан соң 45 көн эчендә тапшырыла. Әлеге срок Комиссия рәисе тарафыннан озайтылырга мөмкин, әмма күп дигәндә 30 көнгә генә.

7. Уведомление, бәяләмә һәм башка материаллар Комиссия тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча комиссия турында нигезләмәгә туры китереп тикшерелә.

Татарстан Республикасының Этил
спирты һәм алкогольле продукция
җитештерүне, әйләнештә йөртүне,
сыйфатын дәүләт тикшерүен тәэмин
итү һәм кулланучылар хокукларын
яклау буенча дәүләт инспекциясенең
дәүләти гражданлык
хезмәткәрләре тарафыннан
мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган
яки китерә алу ихтималы булган
вазыйфаи бурычларны
үтәгәндә
шәхси кызыксынуның килеп
чыгуы турында хәбәр итү тәртибенә

кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт
алкоголь инспекциясе җитәкчесе
И.А.Марченкога

________________________________

...

________________________________дән
(Ф.И.О.вазыйфасы, )

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр бәрелешенә китергән яки китерә алу ихтималы булган шәхси кызыксынуның барлыкка килүе турында
Уведомление

Вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр бәрелешенә китерә торган яки китерә алу ихтималы булган шәхси кызыксынуымның килеп чыгуы турында хәбәр итәм (*кирәклесенең астына сызарга*)

Шәхси кызыксынуның килеп чыгуына нигез булып торган хәлләр:

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Үтәлешенә шәхси кызыксыну йогынты ясый торган яки йогынты ясау ихтималы булган вазыйфаи бурычлар: ______________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

__________________

Мәнфәгатьләр бәрелешен кисәтү яки җайга салу буенча тәкъдим ителә торган чаралар: ____________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Бу уведомлениене карап тикшергәндә Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча комиссиясе утырышнда катнашырга ниялим (ниятләмим) *(кирәклесенең астына сызарга).*

«___» ____________ 20__ ел ____________________________

__________________________________________

(уведомлениене җибәргән зат имзасы ) (тулы имзасы)